ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 27 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 7, № 11; 2004, № 11; 2005, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4; 2008, № 7 (I өлеш); 2009, № 11; 2010, № 10 (II өлеш); 2014, № 3, № 6, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның икенче абзацында «һәм вакытлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 5 статьяның таблицасында «(тулаем сыйдырышлылыгының һәр регистр тоннасыннан)» сүзләрен «(тулаем сыйдырышлылыгының һәр регистр тоннасыннан яисә, тулаем сыйдырышлылыгының үлчәнеше күрсәтелмичә билгеләнгән очракта, тулаем сыйдырышлылык берәмлегеннән)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8 статья. **Салым түләүчеләр – оешмалар тарафыннан салым түләү тәртибе**

Салым түләүчеләр – оешмалар салымны салым чоры узганнан соң, шулай ук хисап чоры йомгаклары буенча салымның аванс түләүләрен Россия Федерациясе Салым кодексында билгеләнгән срокларда түлиләр.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2020 елның 1 гыйнварыннан, ләкин, шушы статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми

басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 3 пунктлары 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты | Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 28 ноябрь
№ 88-ТРЗ